РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ с. Тюлячи КАРАР

«28» февраль 2025ел № 39

**Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 07 маендагы 60 номерлы «Теләче муниципаль районы милкендәге һәм мондый мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече һәм урта эшкуарлык субъектлары сатып ала торган арендалана торган күчемле һәм күчемсез мөлкәтне арендалау өчен түләү срогын билгеләү турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советы» Ассоциациясенең 2025 елның 17 февралендәге № исх-29гр номерлы хатын карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, 2007 елның 24 июлендәге «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 209-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 07 маендагы 60 номерлы «Теләче муниципаль районы милкендәге һәм мондый мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече һәм урта эшкуарлык субъектлары сатып ала торган арендалана торган күчемле һәм күчемсез мөлкәтне арендалау өчен түләү срогын билгеләү турында» карарына, 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«1. Теләче муниципаль районы милкендәге һәм мондый мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече һәм урта эшкуарлык субъектлары сатып ала торган арендалана торган күчемле һәм күчемсез мөлкәтне арендалау өчен түләү срогы күчемсез мөлкәт өчен сигез ел һәм күчемле мөлкәт өчен өч ел тәшкил итә.».

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары – территориаль үсеш бүлеге башлыгы Р.В. Нигъмәтҗановка йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин